ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 17 » февраль 2021 ел** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитетының 11.08.2020, №12 карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, кронлаштыруга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 17.02.2021, №15 “Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитетының 11.08.2020, №12 карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, кронлаштыруга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча өстәргә:

«2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенә салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.».

2) 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.».

3) 3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге соратулар җибәрә:

- күчемсез мөлкәткә хокуклар һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык белешмәләр булган);
- салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычларның булуы (булмавы) турында белешмә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорату.

2. Әлеге карарныТатарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012734